КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 гыйнвар № 27

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2013 ел, 10 июнь, 394 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2013 ел, 10 июнь, 394 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 23 июнь, 456 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставын яңа редакциядә бәян итеп (теркәлгән), үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2013 ел, 10 июнь, 394 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 23 июнь, 456 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\27.docx

«Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставына кушымта

«Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы эмблемасы тасвирламасы

1. «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы символика сыйфатында эмблема куллана.

2. «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы эмблемасы түгәрәк формада. Бөҗраның чикләре зәңгәр төстә. Әйләнә буенча түгәрәкнең эчендә ак төстә язу: «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК ФОНДЫ» КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН ОЕШМАСЫ». Түгәрәкнең үзәгендә аксыл көрән, кызгылт сары һәм кызыл төсләрдәге күпфатирлы йортлар ясалган. Рәсем астында зәңгәр төстәге хәрефләр урнашкан: ТР ТКХ ФОНДЫ – «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы исеменең кыскартылма исеме.

3. «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы эмблемасы бер төстәге рәсем белән ясала ала.

---

F:\KARAR\2016\27-1.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 10 июнь, 394 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 21 гыйнвар, 27 нче
карары редакциясендә)

## «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставы

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды (алга таба – Фонд) фондның оештыру-хокукый формасында әгъзалыгы булмаган махсуслашкан коммерциягә карамаган оешма булып тора. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Фонд Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра орган махсуслашкан коммерциягә карамаган оешма (төбәк операторы) була.

1.2. Фонд үзенең эшчәнлеген Россия Федерациясе Торак кодексы, аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә гамәлгә ашыра.

1.3. Фондны гамәлгә куючы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тора (алга таба – гамәлгә куючы).

1.4. Фондның тулы исеме - «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы.

Фондның кыскартылган исеме – «ТР ТКХ фонды» ККО.

1.5. Фондның урнашу урыны: 420043, Казан шәһәре, Лесгафт урамы, 29 йорт.

1.6. Фонд законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алыну вакытыннан алып юридик зат буларак төзелгән санала, милкендә аерымланган мөлкәте була, үз йөкләмәләре буенча әлеге мөлкәт белән җавап бирә, үз исеменнән мөлкәт хокуклары һәм мөлкәт булмаган хокуклар ала һәм гамәлгә ашыра, бурычлы була, судта дәгъвачы һәм җавап бирүче була ала.

1.7. Фонд эшчәнлек вакыты чикләнми төзелә.

1.8. Фондның мөстәкыйль балансы була. Фонд, әгәр Татарстан Республикасы законнарында каралса, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында исәп-хисап счетлары ачарга хокуклы, махсус счетлардан тыш. Россия Федерациясе Торак кодексында каралган бүтән очракларда фонд тарафыннан исәп-хисап счетларын, бүтән счетларны ачу Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлештә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурс нәтиҗәсендә Фонд

тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган россия кредит оешмаларында гамәлгә ашырыла.

1.9. Фондның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә язылган тулы исеме белән мөһере, үз исеме белән штамплары һәм бланклары, шулай ук әлеге уставка кушымтада тасвирламасы бирелгән эмблемасы була.

1.10. Фондның филиаллар төзергә һәм вәкиллекләр ачарга, шулай ук коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар төзергә, хуҗалыклы җәмгыятьләрнең устав капиталларында, бүтән коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмаларның мөлкәтләрендә катнашырга хокукы юк, әлеге уставның 1.11 пунктында каралган очраклардан тыш.

1.11. Фонд үзенең гомуми мәнфәгатьләрен тәкъдим итү һәм яклау, үз эшчәнлеген яраштыру, үз эшчәнлегенең һәм федераль законнарга каршы килми торган һәм коммерциягә карамаган характерда булган максатларда төбәк операторлары сыйфатында эшчәнлек белән бәйле бүтәннәренең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен көчләрне берләштерү максатларында ассоциацияләр һәм төбәк операторлары берлекләре төзергә, мондый ассоциацияләр, берлекләрнең әгъзалары булырга хокуклы. Фонд үзеннән үзе көйләнә торган оешма әгъзасы булырга хокуклы, әгәр мондый әгъзалык Фонд тарафыннан үзенә йөкләнгән вазыйфаларны үтәү максатларында эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыру кирәклегенә бәйле булса.

1.12. Фонд әлеге Уставта каралган һәм күрсәтелгән максатларга туры килә торган максатларга ирешү өчен керем китерә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыра ала. Бу чакта Фонд эшчәнлекнең мондый төрләре буенча аерым исәп-хисап алып бара.

## 2. Фондның максатлары, предметы, бурычлары һәм вазыйфалары

2.1. Фонд эшчәнлеге максатлары – гражданнарның яшәве өчен имин һәм уңай шартлар тудыру һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга стимуллаштыру, торак фонды белән идарә итүнең нәтиҗәле механизмнарын формалаштыру, ресурсларны саклаучы технологияләрне кулланышка кертү, торак-коммуналь хуҗалык тармагында мәгълүмат-аңлату эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

2.2. Фонд эшчәнлегенең предметы – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь төзәтү үткәрүне мондый күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләре акчасы, бюджет акчасы һәм законнарда тыелмаган бүтән финанслау чыганаклары исәбеннән оештыру һәм үз вакытында башкаруны тәэмин итү өчен акча һәм мөлкәт формалаштыру, шулай ук торак-коммуналь хуҗалык тармагында бүтән программаларны тормышка ашыру.

2.3. Фондның төп бурычы – Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыкны үстерүне, шул исәптән законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь төзәтү үткәрүне тәэмин итү.

2.4. Үз максатларына ирешү өчен Фонд түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашыра:

капиталь төзәтү фондлары формалаша торган күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләре түли торган капиталь төзәтүгә түләүләрне Фонд счетына (счетларына) туплауны;

әгәр күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләре милекчеләрнең гомуми җыелышында Фонды махсус счет хуҗасы итеп сайласа, үз исеменә махсус счетлар ачуны һәм әлеге счетлар буенча операцияләр кылуны. Фондның үз исеменә мондый счет ачудан күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләренә баш тартуга хокукы юк;

күпфатирлы йортларда бүлмәләренең милекчеләре Фонд счетында (счетларында) капиталь төзәтү фондларын формалаштыра торган уртак мөлкәтне капиталь төзәтү буенча техник заказчы вазыйфаларын гамәлгә ашыруны;

күпфатирлы йортларда бүлмәләренең милекчеләре Фонд счетында (счетларында) капиталь төзәтү фондларын формалаштыра торган уртак мөлкәтне капиталь төзәтү үткәрүне капиталь төзәтүнең төбәк программасында каралган күләмдә һәм вакытларда тәэмин итүне;

күпфатирлы йортларда бүлмәләренең милекчеләре Фонд счетында (счетларында) капиталь төзәтү фондларын формалаштыра торган уртак мөлкәтне капиталь төзәтүгә чыгымнарын финаслауны, әлеге капиталь төзәтү фондлары акчасы кысаларында, зарур булганда бүтән чыганаклардан, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яки) җирле бюджеттан алынган акчаны җәлеп итеп;

күпфатирлы йортларда милекчеләре Фонд счетында (счетларында) капиталь төзәтү фондларын формалаштыра торган уртак мөлкәтне капиталь төзәтүне үз вакытында тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара багланышларны;

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү, шул исәптән законнарда билгеләнгән тәртиптә Фонд компетенциясе кысаларында энергия нәтиҗәлелеген һәм энергия саклауны күтәрүне, коммуналь инфраструктураны яңартуны күздә тоткан төбәк программасын тормышка ашыруны;

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтүне оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча консультация, мәгълүмат, оештыру-методик ярдәм күрсәтү, шулай ук торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру, энергия нәтиҗәлелеген һәм энергия саклауны күтәрү, коммуналь инфраструктураны яңарту тармагында бүтән программаларны тормышка ашыруны;

законнарда билгеләнгән тәртиптә капиталь төзәтүгә түләүләр рәвешендә төбәк операторы счетына килгән акчаның исәбен алып баруны;

законнарда каралган һәм Фонд эшчәнлеге максатларына туры килә торган бүтән вазыйфаларны.

2.5. Фонд капиталь төзәтү фондының Фонд счетында формалашкан вакытлыча кулланылмый торган акчасын Россия Федерациясе Торак кодексының 176 нчы статьясында билгеләнгән тиешле таләпләргә туры килә торган кредит оешмаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм шартларда урнаштырырга хокуклы. Бу чакта вакытлыча кулланылмый торган акчаны урнаштырудан алынган керемнәрне Россия Федерациясе Торак кодексының 174 нче статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән максатларга гына файдаланырга мөмкин.

## 3. Фонд мөлкәте

3.1. Гамәлгә куючы яки бүтән затлар ихыярый мөлкәти түләү яки бүтән керемнәр сыйфатында Фондка тапшырган мөлкәт Фонд милке булып санала.

3.2. Фонд мөлкәте түбәндәгеләр исәбеннән формалаша:

гамәлгә куючы түләүләре;

Фонд счетындагы (счетларындагы) капиталь төзәтү фондларын формалаштыручы күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләре түләве;

законнарда тыелмаган башка чыганаклардан, шул исәптән Фондның вакытлыча кулланылмый торган акчасын керем китерә торган эшчәнлеккә инвестицияләүдән, Татарстан Республикасының күпфатирлы йортларындагы уртак мөлкәтне капиталь төзәтүнең төбәк программасын тормышка ашыру максатларында Фонд тарафыннан алынган кредитлар, заемнардан керемнәр.

3.3. Фонд эшчәнлегеннән керемнәр аның карамагында кала һәм әлеге Уставта билгеләнгән максатларга юнәлдерелә.

3.4. Фонд мөлкәте Россия Федерациясе Торак кодексы һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә аның вазыйфаларын үтәү өчен файдаланыла.

3.5. Фонд тарафыннан күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләреннән алынган, Фонд счетындагы (счетларындагы) капиталь төзәтү фондларын формалаштыручы акча әлеге күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтен капиталь төзәтүгә чыгымнарны финанслауга гына тотылырга мөмкин. Әлеге акчаны бүтән максатларда, шул исәптән административ-хуҗалык чыгымнарын түләүдә файдалану рөхсәт ителми.

3.6. Фонд тарафыннан күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләреннән алынган, Фонд счетындагы (счетларындагы) капиталь төзәтү фондларын формалаштыручы акчага Фонд йөкләмәләре буенча түләтү юнәлдерелә алмый, Россия Федерациясе Торак кодексының 44 статьясындагы 2 өлешнең 1.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышы карарлары нигезендә төзелгән шартнамәләрдән, шулай ук подряд оешмалары белән төзелгән әлеге күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзәтү буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкаруга шартнамәләрдән барлыкка килә торган йөкләмәләрдән тыш.

3.7. Фондны банкрот дип таныган очракта күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләреннән алынган, Фонд счетындагы (счетларындагы) капиталь төзәтү фондларын формалаштыручы акча конкурс массасына кертелми.

## 4. Фонд эшчәнлеге белән идарә итү

4.1. Фондны гамәлгә куючы, ул шул исәптән Фондның коллегиаль орган булып тора, түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

гамәлдәге Уставка үзгәрешләр кертү;

Фондның башка органнарын оештыру һәм аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

Фонд эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен, аның мөлкәтен формалаштыру һәм куллану принципларын билгеләү;

Фондның еллык хисапларын һәм еллык бухгалтер (финанс) хисабын раслау;

Фонд тарафыннан хуҗалык җәмгыятьләре төзү турында һәм (яки) Фондның аларда катнашуы хакында карарлар кабул итү;

Фонд филиалларын төзү турында һәм (яки) вәкиллекләрен ачу хакында карарлар кабул итү;

законнарда каралган очракларда Фонд башкарган алыш-бирешләрне хуплау.

4.2. Попечительләр советы, идарә һәм генераль директор Фонд органнары булып тора.

4.3. Фондның Попечительләр советы (алга таба – Попечительләр советы) Фонд эшчәнлегенә, Фондның башка органнары тарафыннан карарлар кабул итүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә, Фонд акчасын файдалануга, Фонд тарафыннан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын һәм әлеге Уставны үтәүгә күзәтчелекне гамәлгә ашыручы коллегиаль орган булып тора.

4.3.1. Попечительләр советы иҗтимагый башлангычларда гамәлдә була, Попечительләр советы әгъзалары Фондта штатта тормый.

4.3.2. Попечительләр советы рәисе гамәлгә куючы карары белән вазыйфасына билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә. Попечительләр советы рәисенең вәкаләтләре вакыты 5 ел тәшкил итә.

4.3.3. Попечительләр советы әгъзалары вәкаләтләре аларны элек сайларга тәкъдим иткән оешмалар яки органнар тәкъдимнәре нигезендә вакытыннан алда туктатылырга мөмкин. Попечительләр советы рәисе вазыйфасына яңа кандидатура бу вазыйфага элек билгеләнгән Попечительләр советы рәисенең вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителүе белән бергә билгеләнә.

4.3.4. Попечительләр советы составы гамәлгә куючы карары белән раслана. Попечительләр советы составына гамәлгә куючы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре керә.

4.3.5. Попечительләр советы вәкаләтләре:

Фонд эшчәнлеген гамәлгә ашыру, Фондның идарә органнары кабул иткән карарларны үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүматны карап тикшерү, шулай ук Попечительләр советы утырышларында мәсьәләләрне карап тикшерү йомгаклары буенча Фондның башка идарә органнары өчен тәкъдимнәр эшләү;

Фонд гамәлгә ашыра торган капиталь төзәтү программасын үтәүне мониторинглау нәтиҗәләрен карап тикшерү;

Фондның бухгалтер исәбен һәм финанс (бухгалтер) хисаплыгын алып баруга ел саен мәҗбүри аудит үткәрү өчен конкурс нигезендә сайлап алынган аудитор оешмасын раслау, шулай ук Фонд эшчәнлегенә ревизияләр һәм бүтән тикшерүләр нәтиҗәләрен карап тикшерү һәм алар буенча карарлар кабул итү;

Фондның еллык финанс (бухгалтер) хисаплыгына аудит үткәрү турында карар кабул итү;

кимендә ярты елга бер тапкыр идарәнең Фонд эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматын карап тикшерү һәм мондый мәгълүматны карап тикшерү йомгаклары буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Фондны ябу өчен нигезләр барлыкка килү мөмкинлеген булдырмау максатларында Фонд эшчәнлеген даими мониторинглауны гамәлгә ашыру;

Законнарда һәм әлеге Уставта каралган бүтән күзәтчелек вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.

4.3.6. Әлеге Уставта каралган Попечительләр советы вәкаләтләрен Фондның бүтән органнарына тапшыру рөхсәт ителми.

4.3.7. Попечительләр советы Фондның бүтән органнарыннан теләсә кайсы кирәкле мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

4.3.8. Попечительләр советы утырышлары кирәк булган саен аның рәисе яки Попечительләр советы әгъзаларының кимендә өчтән бер өлеше тарафыннан чакырыла, әмма кварталга бер тапкырдан да кимрәк түгел.

4.3.9. Попечительләр советы утырышында аның әгъзаларының яртысы катнашса, карарлар кабул итәргә хокуклы. Попечительләр советы карарлары катнашучылар санының өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

4.3.10. Попечительләр советы рәисе яки Попечительләр советы әгъзаларының кимендә өчтән бере башлангычы белән Попечительләр советы утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча (әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләләрдән тыш) тавыш бирү читтән торып үткәрелергә мөмкин.

4.3.11. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта Попечительләр советы әгъзасы үз фикерен язмача белдерә ала, аны мәҗбүри рәвештә Попечительләр советы утырышы беркетмәсенә кертелергә тиеш.

4.3.12. Попечительләр советы утырышы Попечительләр советы рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда Попечительләр советы рәисе вәкаләтләр биргән зат тарафыннан үткәрелә.

4.3.13. Попечительләр советы утырышларында Фондның идарә әгъзалары, генераль директоры катнашырга һәм көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча, Попечительләр советы рәисе белән килештереп, чыгыш ясарга хокуклы.

4.3.14. Попечительләр советы карарлары утырышта рәислек итүче һәм Попечительләр советы секретаре имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.3.15. Попечительләр советы карарлары Фондның идарәсе һәм генераль директоры өчен мәҗбүри булалар.

4.3.16. Попечительләр советы утырышлары беркетмәләре өч ел дәвамында саклана.

4.3.17. Попечительләр советы утырышы Фондның бухгалтер исәбен һәм финанс (бухгалтер) хисабын алып баруга еллык мәҗбүри аудит үткәрүче аудитор оешмасы таләбе буенча чакырылырга мөмкин.

4.3.18. Попечительләр советы әгъзаларының Фондның бүтән органнары эшчәнлегендә катнашырга хокуклары юк.

4.3.19. Попечительләр советы эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү максатларында Попечительләр советы секретаре билгеләнә, аның вазыйфаларына түбәндәгеләр керә:

Попечительләр советы эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү;

Попечительләр советы утырышының көн тәртибен Попечительләр советы рәисенә раслауга тапшыру;

Попечительләр советы утырышын үткәрү урыны, вакыты, көне һәм көн тәртибе турында Попечительләр советы әгъзаларына хәбәр итү;

Попечительләр советы утырышларына материаллар әзерләүне оештыру;

Попечительләр советы утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерү;

законнарда каралган бүтән вазыйфалар.

4.4. Фонд эшчәнлеге белән агымдагы идарә итүне идарә гамәлгә ашыра, ул гамәлгә куючыга хисап бирә.

4.4.1. Идарә составы гамәлгә куючы карары белән раслана. Идарә белән идарә итү идарә әгъзалары арасыннан гамәлгә куючы билгели һәм азат итә торган зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.4.2. Идарә әлеге Устав, шулай ук гамәлгә куючы раслаган идарә турында нигезләмә нигезендә эшли, анда идарә утырышларын чакыру һәм үткәрү вакыты, тәртибе билгеләнә.

4.4.3. Идарә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп кору тармагында чараларны финанслауга өстәмә чыганаклар җәлеп итү, энергия нәтиҗәлелеген күтәрү һәм энергияне саклау, коммуналь инфраструктураны модернизацияләү буенча тәкъдимнәрне карап тикшерү һәм раслау;

Фондның еллык хисабын әзерләү һәм аны Попечительләр советына һәм гамәлгә куючыга җибәрү;

Фондның (бюджетның) керемнәре һәм чыгымнары финанс планын, шул исәптән гамәлгә куючы раслаган күләм кысаларында административ-хуҗалык чыгымнары сметаларын раслау, финанс планын раслау һәм аңарга төзәтмәләр кертү;

Фондның оештыру структурасын, штат расписаниесен раслау, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен (Фонд хезмәткәрләре хокукларын һәм бурычларын, Фонд хезмәткәрләре хезмәтенә түләү зурлыгын һәм рәвешен) билгеләү, Фондның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләрне раслау яисә бу вәкаләтләрне Фондың генераль директорына тапшыру;

Фондның бердәнбер башкарма органы белән хезмәт шартнамәсен төзү, әлеге хезмәт шартнамәсенә үзгәрешләр кертү һәм аны гамәлдән чыгару;

законнарда, әлеге Уставта каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, әгәр әлеге вәкаләтләр Фондның башка органнары вәкаләтләренә карамаса.

4.4.4. Идарә утырышында әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, идарә карарлар кабул итәргә хокуклы. Идарә карарлары катнашучы идарә әгъзаларының өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

4.4.5. Идарә утырышында беркетмә алып барыла, ул идарә әгъзаларына, Попечительләр советына, Фондның бухгалтер исәбен һәм финанс (бухгалтер) хисабын алып баруга еллык мәҗбүри аудит үткәрүче аудитор оешмасына тапшырыла.

4.4.6. Идарә утырышлары идарә рәисе яки ул вәкаләтләр биргән зат тарафыннан үткәрелә. Идарә утырышы беркетмәләре утырышта рәислек итүче һәм идарә секретаре тарафыннан имзалана.

4.4.7. Идарә эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү максатларында идарә секретаре билгеләнә, аның вазыйфаларына түбәндәгеләр керә:

идарә эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү;

идарә утырышының көн тәртибен идарә рәисенә раслауга тапшыру;

идарә утырышын үткәрү урыны, вакыты, көне һәм көн тәртибе турында идарә әгъзаларына хәбәр итү;

идарә утырышларына материаллар әзерләүне оештыру;

идарә утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерү;

законнарда каралган бүтән вазыйфалар.

4.4.8.Идарә әгъзалары үз бурычларын даими нигездә үтиләр.

4.5. Фондың эшчәнлеге белән агымдагы идарәне гамәлгә ашыручы бердәнбер орган сыйфатында генераль директор чыга.

4.5.1. Генераль директорны билгеләү, аны вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре вакытын билгеләү гамәлгә куючы карар белән гамәлгә ашырыла.

Генераль директорны билгеләү конкурс нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Генераль директор торак-коммуналь хуҗалык тармагында дәүләт сәясәтен һәм норматив-хокукый җайга салуны эшләү һәм тормышка ашыру вазыйфаларын башкаручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән мәҗбүри квалификация таләпләренә туры килергә тиеш.

4.5.2. Генераль директор идарә составына кертелә.

4.5.3. Генераль директор түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка оешмалар белән багланышларда Фонд исеменнән гамәлләр кылу һәм ышанычнамәсез Фонд мәнфәгатьләрендә эш итү;

Фонд эшчәнлеге мәсьәләләре буенча җитәкчелек итү документларын (боерыклар, күрсәтмәләр) чыгару;

Фонд хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү;

үзенең урынбасарлары арасында йөкләмәләрне бүлү;

генераль директор компетенциясенә караган бүтән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү, Фондның бүтән органнары компетенциясенә караган мәсьәләләрдән тыш;

Фондның бүтән органнары эше өчен шартлар тудыру һәм аларның карарларын тормышка ашыруны оештыру;

беренче имза хокукы белән Фондның финанс документларын имзалау;

законнар һәм әлеге Устав таләпләре нигезендә исәп-хисап счетларын ачу;

Фонд исеменнән ышанычнамәләр бирү;

Фонд эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка гамәлләр кылу, Фондның бүтән органнарының аерым компетенциясенә караганнарыннан тыш.

4.5.4. Генераль директор гамәлгә куючы һәм Фонд идарәсе кабул иткән карарларның үтәлеше өчен тиешенчә гамәлгә куючы һәм Фонд идарәсе алдында җавап тота.

## 5. Фондның күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләре, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар белән багланышлары

5.1. Күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләре, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар белән багланышлар Фонд тарафыннан Фонд идарәсе раслаган һәм аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырылган регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Фондның бүтән оешмалар белән багланышларын гамәлгә ашырганда мондый багланышларда катнашучыларның мәнфәгатьләре каршылыгы булу мөмкинлеге исәпкә алына.

## 6. Фонд эшчәнлеген тикшерү, хисап һәм аудит

6.1. Фонд эшчәнлегенең законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы башкара.

6.2. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә финанс-бюджет тармагында тикшерү һәм күзәтчелек вазыйфаларын гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы түбәндәгеләрне башкара:

капиталь төзәтүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм сыйфатында алынган чараларны, шулай ук Фонд счетында (счетларында) капиталь төзәтү фондларын формалаштыра торган күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләреннән алынган чараларны фонд тарафыннан файдалануны тикшерүдә тота;

Россия Федерациясе законнары таләпләрен билгеле булган бозуларны бетерү турында Фондка киңәшләр һәм (яки) күрсәтмәләр юллый.

6.3. Татарстан Республикасының финанс тикшерүе органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль финанс тикшерүе органнары, Россия Федерациясе Хисап палатасы, Татарстан Республикасының һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-исәпләү һәм финанс органнары тиешле бюджетлар акчаларын Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә файдалануына финанс тикшерүен гамәлгә ашыралар.

6.4. Фонд ел саен үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында, дәүләт сере, коммерция сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, еллык хисапны һәм аудитор бәяләмәсен бастыра.

6.5. Фонд түбәндәгеләрне үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштыра һәм һәр кызыксынган затка ачык булуын тәэмин итә:

күпфатирлы йортларны капиталь төзәтү мәсьәләләрен җайга салучы Россия Федерациясе норматив хокукый актлары яки Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән каралган очракларда Фонд әзерли торган төрле төрдәге хисаплар;

һәр күпфатирлы йорт буенча капиталь төзәтү фондын формалаштыруның торышы турында мәгълүмат;

Попечительләр советы һәм Фонд идарәсе кабул итә торган карарлар турында мәгълүмат;

Фонд эшчәнлеген тикшерүләр нәтиҗәләре турында мәгълүмат;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, шулай ук әлеге Уставта каралган бүтән мәгълүмат һәм белешмәләр.

## 7. Фондның җаваплылыгы

7.1. Фонд законнар нигезендә җавап тота.

7.2. Фонд счетында (счетларында) капиталь төзәтү фондларын формалаштыручы күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләре каршында үзе җәлеп иткән подряд оешмалары тарафыннан капиталь төзәтү үткәрү буенча йөкләмәләр үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү нәтиҗәләре өчен җавап тота.

7.3. Фонд тарафыннан үзенең йөкләмәләрен үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү нәтиҗәсендә күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләренә китерелгән зыян граждан законнары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

7.4. Фонд үзенең йөкләмәләре буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

## 8. Фондны үзгәртеп оештыру һәм ябу

8.1. Фондны үзгәртеп оештыру рөхсәт ителми.

8.2. Фондны ябу коммерциячел булмаган оешмалар турында законнарда билгеләнгән тәртиптә, фондның оештыру-хокукый формасында оештырылган коммерциячел булмаган оешмалар өчен билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, гомуми тәртиптә башкарыла.

8.3. Фондны ябу турында карарны мәнфәгатьле затларның гаризасы буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәге очракларда суд кабул итә ала:

әгәр Фондның максатларын тормышка ашыру өчен аның мөлкәте җитәрлек булмаса һәм кирәкле мөлкәтне алу мөмкинлеге реаль булмаса;

әгәр Фондның максатлары ирешелә алмаса, ә Фонд максатларын кирәк булганча үзгәртү башкарыла алмаса;

Фонд үзенең эшчәнлегендә әлеге Уставта каралган максатлардан тайпылса;

законнарда каралган башка очракларда.

8.4. Ябыла торган Фондның кредиторлар таләпләрен канәгатьләндерүне исәпләгәннән соң калган мөлкәте Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь төзәтү максатларына юнәлдерелә.

8.5. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына тиешле язу кертелгәннән соң Фонд юридик зат сыйфатында гамәлдә булуыннан туктый.

## 9. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

Әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Әлеге Уставка кертелгән үзгәрешләр аларны дәүләт теркәвенә алганнан соң көченә керә.

---